СОВЕТ ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЛЕБЕДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

04.07.2017 Лебедино авылы № 68

**Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкалары һәм бурычларын түләтү һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслау турында**

Россия Федерациясенең 59 нчы санлы 3 нче пункты һәм Федераль салым хезмәте Бөерыгы нигезендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгының "Пенялар, штрафлар һәм процентлар түләтүгә өметсез дип табылган недоимкаларны һәм бурычларны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә өметсез дип табылган хәлләрне раслаучы документлар исемлегенисәптән чыгару тәртибен раслау турында" гы 19.08.2010 ел, ЯК-7-8-/393@ санлы Законы нигезендә

**Лебедино авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкаларын һәм бурычларын түләтүне һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокук мәгълүматының рәсми карары"нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә халыкка хәбәр итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне үземдә калдырам.

**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И.Тюкарев**

СОВЕТ ЛЕБЕДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Лебедино авыл җирлеге
Советының 04.07.2017,
68 санлы карарына кушымта

**Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар недоимкалары һәм бурычларын түләтү һәм исәптән чыгаруны өметсез дип тануның өстәмә нигезләре**

1. Россия Федерациясе Гражданнар Кодексының 196 нчы маддәсе нигезендәпенялар, җирле салымнар, җыемнар, башка мәҗбүри түләүләр буенча штрафлар, шулай ук аларга исәпләнгән пенялар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтү һәм исәптән чыгару билгеләнгән дәгъва срогы – өч ел узу белән өметсез дип таныла.

2. Әлеге недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларРоссия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары һәм норматив хокук актларында билгеләнгән тәртип һәм документлар нигезендә исәптән чыгарыла.